ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАЧНЫЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк ур., 34

СОВЕТ ДАЧНОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. Дачное, ул. Центральная, 34

тел./факс 8(84365)78-3-33 e-mail: Dach.Vsg@tatar.ru

---

КАРАР
07 август 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 132

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге тарафыннан шәһәр төзелеше өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында**

Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләрне раслау турында”, 2019 елның 30 маендагы 300 номерлы карарын караганнан соң, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. 3 һәм 4 бүлекләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру өлешендә вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә.

Кабул ителә торган вәкаләтләрнең тормышка ашыру предметы булып торалар:
- җирлекнең генераль планын раслау;
- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;
- җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативларын раслау.

2. Дачный авыл җирлеге Башкарма комитетына Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру буенча килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Дачный авыл җирлеге Башлыгына имза куюга тапшырырга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Совет рәисе,
Дачный авыл җирлеге башлыгы Р.А.Жильцов